ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татар Такталы торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында

28.03.2024ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Татар Такталы торак пунктында 2023 елның 27октябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татар Такталы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 2 нче номерлы “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татар Такталы торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында” гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карары нигезендә, Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татар Такталы торак пункты гражданнар җыены

КАРАРЫ:

1. Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Татар Такталы торак пунктында 2023 елның 27 октябрендә кабул ителгән 1 нче номерлы “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татар Такталы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 2 нче номерлы “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татар Такталы торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында” гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертеп, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) Татар Такталы торак пункты территориясен төзекләндерү (грейдировка, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү));

2) Татар Такталы торак пунктында Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) Татар Такталы торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (үзәк су белән тәэмин итү системасын юдырту, кое урнаштыру белән

суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү))".

2. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http:// www. spasskiy.tatarstan.ru Спас муниципаль районы рәсми сайтының Аграмак авыл җирлеге битендә, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АГРАМАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА